Татарстан Республикасы

Казан шәһәре Авиатөзелеш районы “134 нче татар-рус урта гомуми белем бирү мәктәбе”

гомуми белем муниципаль бюджет учреждениесе

| **Каралды:** | **Килешенде :** | **Расланды:** |
|---|---|---|
| МБ утырышы беркетмәсе №1<br>МБ җитәкчесе<br>__________ А.Җ. Зәйнуллина<br>Дата 25.08.2015 | Директор урынбасары<br>_____ ____ Н.Б . Мусина<br>Дата 26.08.2015 | Мәктәп директоры<br>_________ А.С.Петров<br>Педагогик совет утырышы беркетмәсе №1<br>Дата .08.2015 |

***Эш программасы***

Фән- татар әдәбияты

9 нчы “А” сыйныфы, татар төркеме.

Ф.И.О.- Зәйнуллина Альмира Җиһангәрәй кызы, югары квалификацион категорияле

Гамәлдә куллану вакыты- 2015/16 нчы уку елы

Казан- 2015 -2016 нчы уку елы

**Аңлатма язуы**

**Эш программасы түбәндәге документларны исәпкә алып төзелде:**

1. Россия Федерациясе конституциясе 12.12.1993 (РФ Конституциясенә 30.12.2008 елда №6-ФКЗ, 30.12.2008 елда №7-ФКЗ,21.07.2014 елда №11-ФКЗ белән кергән үзгәрешләр исәпкә алынды.
2. Татарстан Республикасы Конституциясе 6.11.1992(үзгәрешләр һәм әстәмәләр белән)
3. .29.12 2012 нче елда кабул ителгән 273 нче номерлы “Россия Федерациясендә Мәгариф турында” Федераль кануны.
4. 22.07. 2013 нче елда кабул ителгән 68 нче номерлы “Мәгариф турында” Татарстан Республикасы кануны.
5.8.07.1992 нче елда кабул ителгән 1560 – XXII номерлы “Татарстан Республикасы дәүләт телләре һәм Татарстан Республикасында башка телләр турында” ТР кануны.
6.. 17.12.2010 елда кабул ителгән 1897 номерлы төп гомуми белем бирүнең(ООО) Федераль дәүләт белем стандарты..
7.ТР Мәгариф министрлыгының 7699/12 номерлы боерыгы, 23.06.2012 ел “Об учебных планах для 1-11 классов школ РТ, реализующих основные образовательные программы начального общего образования и основного общего образования в соответствии с ФГОС общего образования”.
8. ТР Мәгариф министрлыгының 9807/12 номерлы хаты, 13.08.2012 ел “О преподавании татарского государственного языка в общеобразовательных учреждениях РТ” һәм №9777/12 номерлы хаты, 13.08.2012 ел “Об изучении татарского языка и литературы в образовательных учреждениях”.
9.”Рус телендә урта(тулы) гомуми белем бирү мәктәпләре өчен татар теле һәмәдәбиятыннан үрнәк программалар ” 1-11 нче сыйныфлар. Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы, Казан, Татарстан китап нәшрияты, 2011 нче ел. Ф.Г.Галимуллин, З.Н.Хәбибуллина, Ф.Г.Фәрдиева авторлыгында. (программа федераль дәүләт белем стандартларына (ФГОС) нигезләнеп төзелгән).
10. Татарстан Республикасы Мәгариф һәм Фән министрлыгының 2015/2016 нчы уку елында татар телен укыту үзенчәлекләре.Методик тәкъдимнәр.Казан.2014ел
11. СанПиН 2.4.2.2821-10 “Гомуми белем бирү учрежденияләрендә укыту өчен шартлар һәм укытуны оештыруга санитар-эпидемиологик таләпләр” (РФның баш дәүләт санитар табибының 189 нчы номерлы карары. 29.12.2010 ел)
12. Казан шәһәре Авиатөзелеш районы “134 нче татар-рус урта гомуми белем бирү мәктәбе” гомуми белем муниципаль бюджет учреждениесенең 2015/2016 нчы уку елына уку-укыту планы.

**Татар әдәбиятын укытуның максатлары һәм бурычлары:**
матур әдәбият текстларын форма һәм эчтәлек берлегендә аңлап кабул итү, төп әдәби-тарихи мәгълүматларны һәм әдәби-теоретик төшенчәләрне белү;
дөньяга гуманлы караш, гражданлык тойгысы, патриотизм хисләре, әдәбиятка һәм халыкның мәдәни кыйммәтләренә ярату һәм хөрмәт булдыру, ягъни рухи дөньясы бай булган шәхес тәрбияләү;
әдәби текстны эмоциональ кабул итүне, образлы һәм аналитик фикерләүне, иҗади күзаллауны, китап укучы культурасын һәм автор позициясен аңлауны, сәнгать төрләре белән берлектә әдәбиятның сүз сәнгате буларак үзенчәлеге турында карашны; матур әдәбият әсәрләрен мөстәкыйль уку ихтыяҗын; укучыларның телдән һәм язма сөйләмен үстерү;
әдәбият белеменең нигез төшенчәләренә һәм әдәбият тарихының төп факторларына нигезләнеп, әдәби әсәрне уку һәм анализлау;
әсәрләрдәге конкрет-тарихи һәм гомумкешелек эчтәлекне аерып ала белү; телдән һәм язма чыгышларда әдәби тел байлыгыннан дөрес файдалана белү күнекмәләре булдыру.

Укыту планында 9 нчы сыйныфта татар әдәбиятыннан атнага 2 сәгать вакыт бирелә.  Программада 68 сәгать каралган: язучы иҗаты – 54 сәгать. Класстан тыш уку –4 сәгать, бәйләнешле сөйләм үстерү – 10 сәгать.

**Укыту планы буенча атнага сәг.саны: 2сәг  (9 нчы сыйныф татар әдәбияты, татар төркеме)**

| **1ч** | **2ч** | **3ч** | **4ч** | **еллык** |
|---|---|---|---|---|
| 18 | 14 | 20 | 16 | 68 |

**Практик өлеше**

| **Исеме** | **1ч** | **2ч** | **3ч** | **4ч** | **еллык** |
|---|---|---|---|---|---|
| **Класстан тыш уку** | **2** | | **1** | **2** | **5** |
| **БСҮ** | **1** | **2** | **2** | **2** | **7** |
| **Шигырь ятлау** | **1** | **1** | **1** | | **3** |
| **Сочинение** | **1** | **1** | **1** | **1(к)** | **4** |

**Программаның эчтәлеге**

| № | Төп темалар | Сәг. | Белем һәм күнекмәләр |
|---|---|---|---|
| 1 | Татар халык авыз иҗаты. Риваятьләр һәм легендалар | 2 | Халык авыз иҗаты буларак риваятьләр һәм легендалар. Риваятьләр һәм легендалардан үрнәкләр. Аларның жанр үзенчәлекләре |
| 2 | Язучы иҗатына анализ Шәриф Камал | 2 | Тормыш юлы. Иҗаты. “Буранда” хикәясе. Анда күтәрелгән төп мәсьәләләр, образларның бирелеше |
| 3 | Хөснул Вәлиуллин | 1 | Композиторның иҗаты турында белешмә. “ Акчарлаклар” җыры |
| 4 | Һади Такташ | 2 | Шагыйрьнең татар поэзиясендә тоткан урыны. “Мокамай” шигыре. Лирик геройның Мокамайга мөнәсәбәте |
| 5 | Хәсән Туфан. | 3 | Иҗаты турында белешмә. “Туган тел турында җырлар”, “Кайсыгызның кулы җылы?”,  “Кем  сез?” шигырьләре. Аларның темаларын билгеләү, идеясен ачу |
| 6 | Мирсәй Әмир | 6 | Тормыш юлы, иҗады турында белешмә. “Агыйдел” повесте. Әсәрдә 30 нчы еллар башындагы тарихи вакыйгалар, повесьта табигать күренешенең бирелеше. Пейзаж, аның әһәмияте. |
| 7 | Фәхри Насретдинов | 1 | Опера сәнгатен үстерүдәге эшчәнлеге. |
| 8 | Шамил Усманов | 3 | Тормыш юлы. Иҗаты. “ Гает корбаны” хикәясе. Әсәрнең идеясе, төп герой образы |
| 9 | Фатыйма Ильская, Гөлсем Камская | 1 | Тормыш юлы. Иҗаты. Аларның театр сәнгатен үстерүдәге эшчәнлекләре |
| 10 | Шәриф Еникеев | 5 | Тормыш юлы. Иҗаты. “ Солтангәрәйнең язмышы “ повесте. Тормыштагы авырлыкларны җиңә алуның әсәрдә сурәтләнеше |
| 11 | Самат Шакир | 4 | Тормыш юлы. Иҗаты. “Үлемнән көчлерәк” очеркы. Патриот шагыйрь Хәйретдин Мөҗәй образы һәм аның батырлыгы. Очерк турында төшенчә |
| 12 | Аяз Гыйләҗев | 4 | Тормыш юлы. Иҗаты. “Җомга көн кич белән...” повесте. Бибинур әбинең изгелеге, шәфкатьлелеге. Тормыш авырлыгын җиңүгә ярдәм иткән сыйфатлар. Авторның кешеләрдә яхшылык сыйфатларының кими баруга борчылуы. |
| 13 | Илдар Юзеев | 4 | Тормыш юлы. Иҗаты. “Таныш моңнар”, “Гашыйклар тавы” әсәрләре. Хезмәткә намуслы караш, мәхәббәтнең көче, аңа тугрылык, табигатьне саклау мәсьәләләре. |
| 14 | Рәссам Лотфулла Фәттахов | 1 | Тормыш юлы. Иҗаты. “Игеннәр өлгерде” картинасы. Анда сурәтләнгән вакыйгалар, төсләрнең бирелеше |
| 15 | Фәнис Яруллин | 4 | Тормыш юлы. Иҗаты. “Иң гүзәл кеше икәнсез”, “Ана”, “Җилкәннәр җилдә сынала” әсәрләре. Укытучыга соклану хисенең, ананың баласына булган олы мәхәббәтенең сурәтләнеше. Автобиографик әсәрләрнең үзенчәлеге |

| | | | |
|---|---|---|---|
| 16 | Миргазыян Юныс | 4 | Тормыш юлы. Иҗаты. “Шәмдәлләрдә генә утлар яна” повесте. Бөек Ватан сугышы вакыйгаларының чагылышы. Персонажларның эчке кичерешләре сурәтләнү, татар халкының гореф-гадәтләре һәм йолаларының тасфирлануы |
| 17 | Мәдинә Маликова | 3 | Тормыш юлы. Иҗаты. “Чәчкә балы ” повесте. Гаиләдә хезмәт роле. Яшьләрдә сәламәт яшәү рәвешен тәрбияләү. |
| 18 | Нажар Нәҗми | 1 | Тормыш юлы. Иҗаты. “Татар теле” шигыре. Анда туган телнең бөеклеге чагылдырылу. |
| 19 | Милли бәйрәмнәр. | 1 | Корбан гаете. Мәчетләр тарихы |
| 20 | Дәрестән  тыш уку | 4 | |
| 21 | Бәйләнешле сөйләм үстерү | 10 | |
| | | 68 сәг. | |

2015- 2016 нчы уку елына арадаш аттестация.

**Үткәрү формасы: сочинение -фикерләмә.**

***Укучыларның әзерлек дәрәҗәсенә таләпләр:***

сүз сәнгатенең образлы табигате;
өйрәнгән әдәби әсәрнең эчтәлеге;
классик әдипләрнең тормыш һәм иҗат юлларының төп факторлары;
өйрәнгән әдәби-теоретик төшенчәләр;
әдәби текстны кабул итү һәм анализлау;
әдәби текстның мәгънәви өлешләрен аерып чыгару, укыган буенча тезислар һәм план төзү;
әдәби әсәрнең төрен һәм жанрын ачыклау;
укыган әсәрнең темасын, проблемасын, идеясын ачыклау;
геройларга характеристика бирү;
сюжет, композиция үзенчәлекләрен, махсус сурәтләү чараларының ролен ачу;
әдәби әсәрдәге эпизодларны һәм геройларны чагыштыру;
автор позициясен ачыклау;
укыганга үзеңнең мөнәсәбәтеңне белдерү;
әсәрне (өзекне) сәнгатьле итеп уку;
кабатлап сөйләүнең төрләреннән файдалану;
өйрәнелгән әсәргә бәйле телдән һәм язмача фикерне белдерү;
укыган әсәр буенча фикер алышуда катнашу, фикерләреңне дәлилле белү;
укыган әсәрләргә бәяләмә (отзыв) язу;
татар әдәби теленең нормаларына нигезләнеп, кирәкле темага телдән һәм язмача бәйләнешле текст төзү;
эстетик зәвыкка туры килә торган әдәби әсәрләрне сайлау һәм аларны бәяләү;

аерым автор, аның әсәре, гомумән әдәбият турында кирәкле белешмә әдәбият, вакытлы матбуга, Интернет чаралары һ.б. аша эзләү.

**Укыту – методик комплекты**

1. ”Рус телендә урта (тулы) гомуми белем бирү мәктәбендә татар телен һәм әдәбиятын укыту программасы” 1-11 нче сыйныфлар. Татарстан Республикасы Мәгариф министрлыгы, Казан, “Татарстан китап” нәшрияты, 2011 ел.
2. Дәреслек. 9 нчы сыйныфта татар әдәбияты дәреслеге. (З.Н Хәбибуллина, Х.Г.Фәрдиева, Ә.Н. Хуҗиәхмәтов. - Казан: “Татарстан китап ” нәшрияты, 2011.)

**Өстәмә әдәбият**

**1.**Әдәби әсәргә анализ ясау: Урта гомуми белем бирү мәктәбе укучылары, укытучылар, педагогика колледжлары һәм югары уку йортлары студентлары өчен кулланма/Д.Ф.Заһидуллина, М.И.Ибраһимов,В.Р.Әминева.- Казан:Мәгариф,2005

2. ”Мәгариф” журналлары.

**Календарь тематик план (9 сыйныф, әдәбият)**

| № | Дәрес темасы | Сәгать саны | Дәрестә кулланылган эш төрләре | Белем тикшерү төре | Көтелгән нәтиҗәләр | Дата | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 1 | Халык авыз иҗаты. Риваятьләр. | 1 | Халык авыз иҗаты әсәрләрен искә төшерү | риваятьләр язып | Риваятьләрнең үзенчәлекләрен аңлату , китаплар тәкъдим итү. Риваять , легендаларның аермалы һәм охшаш якларын күрсәтү. | План | Факт |
| 2 | Халык авыз иҗаты.Легендалар. | 1 | Әңгәмә, укытучы сүзе, укучы сөйләме, фикер алышу, дәреслек материалы б/н танышу | Легенда язып алу | “Телләрдән төшмәс Казан” , Казан, 1992 һәм “Казан ” журналы китапханәсе китабында басылган риваятьләр һәм легенда – лар белән таныштыру | | |
| 3 | Шәриф Камал.Тормыш юлы | 1 | Язучының тормыш юлы, иҗаты турында белешмә бирү | Сорауларга җавап | Язучы турында белешмә.Хикәя жанры | | |

| | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | һәм иҗаты. | | | | белән танышу. | | |
| 4 | Ш.Камал “Буранда” хикәясе.Табигатьнең кеше күңеленә тәэсиренең тасвирлануы. | 1 | “Буранда” хикәясен уку | Әсәрне анализлау | Әсәрдә күтәрелгән төп мәсьәләләрне билгеләү, образларга характеристика бирү. | | |
| 5 | .Ш.Камалның “Акчарлаклар” повесте. Табигать күренешләренең кеше нең  эчке кичерешләренә тәэсиренең тасвирлануы. **КТУ№1** | 1 | Әңгәмә, укытучы сүзе, укучы сөйләме,  фикер алышу, дәреслек материалы б/н танышу | Эчтәлеге буенча фикерләр | Язучы әсәрләрендәге табигать күренешләренең сурәтләнеше (пейзаж), кешенең эчке кичерешләренә тәэсирен ачыклау. | | |
| 6 | Композитор Х.Вәлиуллин . “Акчарлаклар”җыры. Авторның музыка өлкәсендәге урыны. | 1 | Композиторның иҗаты турында белешмә бирү. дәреслек материалы б/н танышу | Җырны өйрәнү | “Шүрәле” балетының авторы Ф.Яруллинның әнисе Нәгыймә апа- Хәерби кызы турында мәгълүмат бирү. | | |
| 7 | Һади Такташ. Шагыйрьнең татар поэзиясендә тоткан урыны. | 1 | Һ.Такташның тормыш юлы иҗаты турында мәгълүмат бирү; дәреслек материалы б/н танышу | Иҗаты буекнча тестлар | Илсөяр Ихсанова – Саралан кызы.  “Такташка хат” поэмасы белән таныштыру | | |
| 8 | Һ.Такташның “Мокамай” поэмасы. Лирик геройның Мокамайга мөнәсәбәте. | 1 | “Мокамай” поэмасын уку, фикер алышу. | Өзекне яттан сөйләү | Лирик геройның Мокамайга мөнәсәбәтен ачыклау,әсәрдәге тел-сурәтләү чараларын тикшерү. | | |
| 9 | Хәсән Туфан турында белешмә. “Кайсыгызның кулы | 1 | Х.Туфанның тормыш юлы иҗаты турында мәгълүмат бирү, дәреслек | Иҗаты буенча сорауларга җавап бирү | “Кайсыгызның кулы җылы?” шигыре | | |

| | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | жылы?” шигыре | | материалы б/н танышу | | | | |
| 10 | Х.Туфан. “Туган тел турында җырлар” шигыре. | 1 | Әңгәмә, укытучы сүзе, укучы сөйләме, фикер алышу, дәреслек материалы б/н танышу | **Яттан сөйләү** | Шигырьнең эчтәлеген укучыларга төшендерү,темасын, идеясен ачыклау. | | |
| 11 | Х.Туфан.”Кем сез?”шигыре. | 1 | Әңгәмә, укытучы сүзе, укучы сөйләме, фикер алышу, дәреслек материалы б/н танышу | **Яттан сөйләү** | Шигырьнең эчтәлеген укучыларга төшендерү,темасын, идеясен ачыклау. | | |
| 12 | Х.Туфанның “Гүзәл гамь” җыентыгы **Кту№2** | 1 | Әңгәмә, укытучы сүзе, укучы сөйләме, фикер алышу, дәреслек материалы б/н танышу | Фикер алышу | Җыентыктагы бер шигырьгә анализ ясау. | | |
| 13 | Мирсәй Әмир. Тормыш юлы, иҗаты. | 1 | Язучының тормыш юлы һәм иҗаты турында белешмә бирү, дәреслек материалы б/н танышу | Сорауларга җавап | Мирсәй Әмир иҗатынын әдәбиятта тоткан урынын ңлау | | |
| **14** | М. Әмирнең “Агыйдел” повесте.Әсәрдә таби гать күренешләренең бирелеше. | 1 | Әңгәмә, укытучы сүзе, укучы сөйләме, фикер алышу, дәреслек материалы б/н танышу | Әсәрне анализлау | Әсәрдәге табигать күренешләренә игътибар итү, һәм аның әһәмиятен ачыклау. | | |
| **15** | М.Әмир.”Агыйдел”повесте.Пейзаж һәм аның әһәмияте. | 1 | Әңгәмә, укытучы сүзе, укучы сөйләме, фикер алышу, дәреслек материалы б/н танышу | Әсәрне анализлау. | Пейзаж һәм аның әһәмиятен ачыклау. | | |
| **16** | М.Әмир.”Агыйдел” повесте.Образлар бирелеше. | | Әңгәмә, укытучы сүзе, укучы сөйләме, фикер алышу, дәреслек материалы б/н танышу | Образларга характеристика | Артыкбикә образына характеристика бирү. | | |
| 17 | М.Әмир.”Агыйдел”повесте.Әсәрдә30нчы | 1 | “Агыйдел” повестен уку.фикер алышу | Әсәрне тулысынча анализлау | Әсәрдә бирелгән 30 нчы еллар башындагы | | |

| | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | еллар башындагы вакыйгаларның тасвирлануы | | | Өзекне яттан сөйләү | вакыйгалар белән танышу, язучының тел стилен һәм сурәтләү чараларын тикшерү | | |
| 18 | Табигать һәм без. .Сочинение. **Бсү№1** | 1 | Әңгәмә, укытучы сүзе, укучы сөйләме, фикер алышу, дәреслек материалы б/н танышу | Сочинение язу | “Агыйдел повестенә бәйләп, табигать турында фикер алышу,сочинение язу. | | |
| 19 | Җырчы Фәхри Насретдинов иҗаты Аның опера сәнгатендәге урыны.. | 1 | Җырчы Фәхри Насретдинов б/н танышу җыр тыңлау | Сорауларга җавап | Җырчының опера сәнгатен үстерүдәге эшчәнлеге | | |
| 20 | Шамил Усмановның тормыш юлы һәм иҗаты | 1 | Ш.Усмановның тормыш юлы, иҗаты турында белешмә, дәреслек материалы б/н танышу | Иҗаты турында сорауларга җавап | Шамил Усмановның тормышта һәм әдәбиятта тоткан урынын аңлау. | | |
| 21 | **Ш**.Усманов “Гает корбаны” хикәясе. | 1 | Әңгәмә, укытучы сүзе, укучы сөйләме, фикер алышу, дәреслек материалы б/н танышу | Образга характеристика | Әсәрнең идеясен ачу. Төп геройга характеристика. | | |
| 22 | Ш.Усманов”Гает корбаны.”Төп образны һәләкәткә китергән сәбәпне ачыклау. | | Әңгәмә,фикер алышу,әсәрне өйрәнүне дәвам итү | анализ | Төп образны һәләкәткә китергән сәбәпне ачыклау. | | |
| 23 | “Батырлыкны син ничек аңлыйсың?” **Бсү№2** | 1 | Әңгәмә, укытучы сүзе, укучы сөйләме, фикер алышу, дәреслек материалы б/н танышу | Хикәя язу | Тылдагы батырлык турында әсәрләр. Бөек Ватан Сугышына өлеш керткән геройларны, хезмәт ветераннарын барлау. | | |
| 24 | Артистка Фатыйма Ильская .Театр сәнгатендә тоткан урыны. | 1 | Артистар турында белешмә, дәреслек материалы б/н танышу | Сорауларга җавап | Читтән торып Г.Камал театрына сәяхәт итү, Артистларның театр сәнгатенде тоткан урыны | | |

| | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | | | |
| 25 | Гөлсем Камская.Театр сәнгатендә тоткан урыны. | 1 | Артистның иҗаты белән танышу. | Сорауларга җавап | Артистның театр сәнгатендә тоткан урыны. | | |
| 26 | Сочинение “Казанда яшәгән бөек шәхесләр” **Бсү №3** | 1 | Әңгәмә, укытучы сүзе, укучы сөйләме, фикер алышу, өстәмә материал белән танышу | Сочинение | Бөек шәхесләрне барлау. | | |
| 27 | Ш. Еникеевның тормыш һәм иҗат юлы. “Солтангәрәйнең язмышы” әсәре. | 1 | Тормыш һәм иҗат юлы турында белешмә. Дәреслек белән эш. | Сорауларга җавап | “Солтангәрәйнең язмышы” әсәре белән танышу. | | |
| 28 | Ш. Еникеев “Солтангәрәйнең язмышы”әсәрендә кеше язмышы. | 1 | Әсәрнең эчтәлеге белән танышу. План төзү. Анализ ясау. | анализ | Әсәрне анализларга өйрәнү. | | |
| 29 | Ш. Еники “Солтангәрәйнең язмышы”. Иртәнге табигать күренешенең тасвирланышы. | 1 | Әңгәмә, укытучы сүзе, укучы сөйләме, фикер алышу, дәреслек материалы б/н танышу | Анализ | Тормыштагы авырлыкларны җиңә алуның сурәтләнеше. | | |
| 30-31 | Ш Еники“Солтангәрәйнең язмышы”әсәрендә кешедәге киң күңеллелекнең тасвирлануы. Ш. Еники “Солтангәрәйнең язмышы” әсәрендә авырлыкларны җиңә | 2 | Әңгәмә, укытучы сүзе, укучы сөйләме, фикер алышу, дәреслек материалы б/н танышу | Анализ. Образга характеристика язу | Тормыштагы авырлыкларны җиңә алуның сурәтләнеше. | | |

| | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | алуның сурәтләнеше. | | | | | | |
| 32 | Самат Шакир тормыш юлы һәм иҗаты турында белешмә.Анының әдәбиятта тоткан урыны. | 1 | Язучының тормыш юлы, иҗаты турында белешмә,дәреслек материалы б/н танышу | Сорауларга җавап | Самат Шакир иҗатынын әдәбиятта тоткан урыны | | |
| 33-34 | Самат Шакир. “Үлемнән көчлерәк” очеркы. Әсәрдә фашистлар ерткыычлыгының сурәтләнеше. | 2 | Әңгәмә, укытучы сүзе, укучы сөйләме, фикер алышу, дәреслек материалы б/н танышу | Сорауларга җавап | “Үлемнән көчлерәк” очеркында фашистлар ерткычлыгы тасвирланышы; Совет солдатларының батырлыгы турында әңгәмә. | | |
| 35 | С. Шакир “Үлемнән көчлерәк” очеркында Х.Мөҗәйнең лагерьдагы тормышының тасвирланышы. | 1 | Әсәрне укуны девам итү, фикер алышу, дәреслек материалы б/н танышу | анализ | Патриот шагыйръ Хәйретдин Мөҗәй образы, аның батырлыгы. “Сөт” очеркы һәм шигырьләрен уку | | |
| 36 | С. Шакир “Үлемнән көчлерәк” очеркында төп герой батырлыгының тасвирлануы.. | 1 | Әңгәмә, укытучы сүзе, укучы сөйләме, фикер алышу, дәреслек материалы б/н танышу | Образга характеристика | “Үлемнән көчлерәк” әсәренең очерк булуын раслау.Әдәби һәм публицистик очерк турында мәгълүмат бирү. | | |
| 37 | Аяз Гыйләҗев.Тормыш юлы һәм иҗаты.Әдәбиятта тоткан урыны. | 1 | Язучының тормыш юлы, иҗаты турында белешмә дәреслек материалы б/н танышу | тестлар | Аяз Гыйләҗев иҗатының әдәбиятта тоткан урыны | | |
| 38 | А.Гыйләҗев “Җомга көн кич белән...” әсәре .Бибинурдагы кешелеклелек сыйфатлары тасвирланышы | 1 | Әңгәмә, укытучы сүзе, укучы сөйләме, фикер алышу, дәреслек материалы б/н танышу | Анализ | Бибинурдагы кешелеклелек сыйфатлары, әсәрдәге тел-сурәтләү чаралары. | | |
| 39 | А. Гыйләҗев “Җомга | 1 | Әсәрне укуны девам итү, фикер | анализ | Әсәрдә Бибинурның | | |

| | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | көн кич белән...”әсәреТормыш авырлыгын җиңүгә ярдәм иткән сыйфатларның сурәтләнеше | | алышу, дәреслек материалы б/н танышу | | тормыш авырлыгын җиңүгә ярдәм иткән сыйфатлары | | |
| **40-41** | “Җомга көн кич белән...”1.Бибинурның бәхет төшенчәсенә карашы.2.Балаларның анага мөнәсәбәтенең тасвирлануы. | **2** | Әңгәмә, укытучы сүзе, укучы сөйләме, фикер алышу, дәреслек материалы б/н танышу | Әсәрне тулвсынча анализлау Бибинур образына характеристика язу | Әсәрнең эчтәлеген аңлап, нәтиҗә ясый белү, Фикерләү сәләтенең үсүе. | | |
| 42 | А.Гыйләҗев “Күзгә-күз” әсәре **Кту№3** | 1 | “Күзгә-күз” әсәрен уку. | фикерләр | А.Гыйләҗевнең “Күзгә-күз” әсәре буенча фикер алышу. | | |
| 43 | Илдар Юзеев.Тормыш юлы һәм иҗаты турында белешмә. | 1 | Илдар Юзеевның тормыш юлы, иҗаты турында белешмә. дәреслек материалы б/н танышу | Сорауларга җавап | “Таныш моңнар” .поэмасы | | |
| 44-45 | И. Юзиеев “Гашыйклар тавы” әсәре1.Хезмәткә намуслы карашның бирелеше. 2. Мәхәббәт көченең тасвирлануы. | 2 | “Гашыйклар тавы” әсәрен уку, фикер алышу, дәреслек материалы б/н танышу | Сәнг. уку. | Туган ягыннан, сөйгәненнән аерылу кешегә нинди газаплар китерүен ачыклау | | |
| 46 | И. Юзиев “Гашыйклар тавы” әсәрендә авылны таркалуга китергән сәбәпләр. | 1 | Әңгәмә, укытучы сүзе, укучы сөйләме, фикер алышу, дәреслек материалы б/н танышу | | Әсәрдә күтәрелгән төп проблемалар. | | |
| 47 | “Яшьлек –кеше гомеренең чәчәкле чагы” **Бсү№4Сочинение.** | 1 | Әңгәмә, укытучы сүзе, укучы сөйләме, фикер алышу, дәреслек материалы б/н танышу | Сочинение | Укучыларның фикерләү сәләтен үстерү | | |

| | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 48 | Рәссам Лотфулла Фәттахов.<br>“Игеннәр өлгерде” картинасы<br>**Бсү №5 Анда сурәтләнгән образлар,төсләрнең бирелеше.** | 1 | Рәссам Л.Фәттаховның иҗаты турында белешмә. фикер алышу, дәреслек материалы б/н танышу | Телдән журнал | “Игеннәр өлгерде” картинасын аңларга өйрәнү; картина геройларының икмәккә карата мөнәсәбәтен билгеләү, игенче хезмәтенең иң борынгы ,иң гүзәл хезмәт икәнен искәртү. | | |
| 49 | “Икмәк – ил терәге” **Бсү№6** | 1 | Әңгәмә, укытучы сүзе, укучы сөйләме, фикер алышу, дәреслек материалы б/н танышу | Сочинение | Укучыларнын фикерләү сәләтен үстерү. | | |
| 50 | “Казанда яшәгән бөек кешеләр”БСҮ.№7.Н.И. Лобачевский,Н.Н.Зинин,А.М.Бутлеров,К.Насыйри,Ш.Мәрҗани,Р.Фәхретдинов һ.б.б | 1 | Әңгәмә, укытучы сүзе, укучы сөйләме, фикер алышу, дәреслек материалы б/н танышу | тестлар | Казан шәһәре тарихы, бөек кешеләр белән танышу. | | |
| 51 | Фәнис Яруллин. “ Җилкәннәр җилдә сынала” повесте. | 1 | “ Җилкәннәр җилдә сынала” повестен уку, фикер алышу, дәреслек материалы б/н танышу | Иҗаты буенча тестлар | “Җилкәннәр җилдә сынала “ повесте. Фәниярга тирә-юньдәге кешеләрнең ярдәме. | | |
| **52-53** | Ф. Яруллин“ Җилкәннәр җилдә сынала” повестенда батырлыкның тасвирлануы..<br>.2. Ихтыяр көче,кеше язмышы мәсьәләсенең бергә үрелеп бирелүе. | 2 | Әсәрне укуны девам итү, фикер алышу, дәреслек материалы б/н танышу | Әсәрне тулысынча анализлау.<br>“Җилкәннәр җилдә сынала” сочинение язу | Әсәрдәге образларны бәяләү. Автобиографик әсәрләрнең үзенчәлеге. | | |
| 54 | Ф.Яруллин “Ана “балладасы. Ана мәхәббәтенең сурәтләнүе. | 1 | “Ана балладасы белән танышу,эчтәлегенә төшенү,ана образын бәяләү.<br>фикер алышу, дәреслек материалы б/н | **Яттан сөйләү** | Әдәбият теороиясе. Баллада жанры. | | |

| | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | танышу | | | | |
| 55 | Ф.Яруллин “Иң гүзәл кеше икәнсез” шигыре. Укытучыга соклану хисенең тасвирлануы. | 1 | Әңгәмә, укытучы сүзе, укучы сөйләме, фикер алышу, дәреслек материалы б/н танышу | Җырны җырлау | Җырның тарихы эчтәлеге белән танышу, көен тыңлау . | | |
| 56 | Ф.Яруллинның “Яши белү” әсәре. **Кт**у №4 | 1 | “Яши белү” әсәрен уку, фикер алышу, дәреслек материалы б/н танышу | Уку, эчтәлеге буенча фикерләр. | | | |
| 57 | Миргазиян Юныс.Шәмдәлләрдә генә утлар яна.Бөек Ватан сугышы вакыйгаларының чагылышы. | 1 | М.Юнысның тормыш юлы, иҗаты турында белешмә. фикер алышу, дәреслек материалы б/н танышу | Сорауларга җавап | “Шәмдәлләрдә генә утлар яна “ повестенда Бөек Ватан сугышы чагылышы. | | |
| 58 | М. Юныс “Шәмдәлләрдә генә утлар яна” повестенда персонажларның эчке кичерешләренең сурәтләнүе. | 1 | Әңгәмә, укытучы сүзе, укучы сөйләме, фикер алышу, дәреслек материалы б/н танышу | План төзү, сөйләү | Персонажларның эчке кичерешләре сурәтләнүе. | | |
| 59 | М. Юныс “Шәмдәлләрдә генә утлар яна “ повесте. 1.Җирдән аерылган мизгелдә хисләр кичерелешенең бирелеше. | 1 | Әсәрне укуны девам итү, фикер алышу, дәреслек материалы б/н танышу | анализ | Әсәрдә җирдән аерылган мизгелдә хисләр кичерелешенең бирелеше. | | |
| 60 | “Шәмдәлләрдә генә утлар яна “ повесте Татар халкының гореф-гадәт һәм йолаларының тасвирлануы. | 1 | Әсәрне укуны девам итү, фикер алышу, дәреслек материалы б/н танышу | анализ | Әсәрдә татар халкының гореф-гадәт, йолаларының тасвирлануы. | | |
| 61 | Мәдинә Маликованың тормыш юлы һәм | 1 | Әңгәмә,укытучы сүзе,укучы сөйләме,дәреслек материалы белән | Сорауларга җавап | Язучының әдәбиятт атоткан урыны. | | |

| | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | иҗаты. | | эш. | | | | |
| 62-63 | Мәдинә Маликова “Чәчкә балы”1.Гаиләдә хезмәтнең роле тасвирлануы. Яшьләрдә сәламәт яшәү рәвешен тәрбияләүнең тасвирлануы. | 2 | Әңгәмә, укытучы сүзе, укучы сөйләме, фикер алышу, дәреслек материалы б/н танышу | анализ | “Чәчкә балы ” повесте. Гаиләдә хезмәтнең роле. Яшьләрдә сәламәт яшәү рәвешен тәрбияләү. | | |
| 64 | Мәдинә Маликова “Чәчкә балы” .**КТУ Әсәрнең тулы эчтәлеге белән танышу.** | 1 | Әсәрне укуны дәвам итү, фикер алышу. | Тулы әсәрне уку, фикер алышу | “Чәчкә балы ” повесте. Гаиләдә хезмәтнен роле. Яшьләрдә сәламәт яшәү рәвешен тәрбияләү. | | |
| 65<br>-66 | Нажар Нәҗми. “Татар теле” шигыре.<br>1.Туган телнең авыр язмышын һәм бөеклеген чагылдыру. Мәчетләр тарихы | 1<br>1 | Н.Нәҗминең тормыш юлы,иҗаты турында белешмә.<br>фикер алышу, дәреслек материалы б/н танышу | **Яттан сөйләү** | Татар теле “ шигырен анализлау.<br><br>Мәчетләр тарихы турында мәг-лы булу. | | |
| 67 | Арадаш аттестация эше | 1 | Аттестация эше белән танышу, мөстәкыйль үтәү | | | | |
| 68 | Тел тарихы – халык тарихы. Милли бәйрәмнәр турында сөйләшү<br>**Бсү№9** | 2 | Әңгәмә, укытучы сүзе, укучы сөйләме, фикер алышу, дәреслек материалы б/н танышу | | Корбан бәйрәме. | | |

**Кушымта**

**Арадаш аттестация эше (С өлеше)**

**Балык тоту.** (А. Алиш)

(1) Әтисе белән бергәләп, Таҗи балык тотарга барды. (2) Көн әле бик иртә. (3) Кояш та юк, ә шулай да якты. (4) Су өсте тып-тын. (5) Өф иткән җил дә юк.

(6) Билгеле, мондый вакытта балыклар яхшы чиртәләр, кармакны бер дә тик тотмыйлар. (7) Калкавычны сөйрәп, су төбенә алып төшеп китәләр. (8) Таҗиның әтисе балыкларны сөйри дә чыгара, сөйри дә чыгара. (9) Ялтырап торган ап-ак чабакларны, көмеш тәңкәле кызылканатларны, әрсез алабугаларны. (10) Таҗи аларның барысын да чиләккә җыя бара. (11) Менә инде аларның балык сала торган чиләкләре дә тулып килә. (12) Балык бик шәп эләгә. (13) Шуңа күрә вакытның үтүе дә тоелмый. (14) Әнә инде кояш та күптән күтәрелеп килә. (15) Таҗи аны сизмәде дә. (16) Төшлеккә җитә башлагач, кояш бик нык кыздырырга тотынды. (17) Монысын Таҗи да тойды. (18) Әтисе дә. (19) Әтисе, кесәсендәге кулъяулыгын алып, маңгаендагы тирләрен сөртте. (20) Ә Таҗи:

– Фу... нәрсәгә кирәк булды инде бу кояш, – дип, зәңгәр күктән елмаючыны тиргәргә тотынды.

(21) – Кемгә кирәк, кемгә кирәкми, – диде әтисе, шуннан тагын ялгады, – кояш бер дә булмаса, һаман төн генә булыр иде, ә төнлә балыклар эләкмиләр. (22) Кояш булмаса, җир өстендә үсемлекләр дә үсмәс, син дә, мин дә булмас идек, – диде. (173сүз).

**“Кояш булмаса, җир өстендә үсемлекләр дә үсмәс, син дә, мин дә булмас идек, – диде.”** җөмләсендә әйтелгән фикерне сез ничек аңлыйсыз? Фикерегезне раслау өчен, укылган тексттан 2 мисал китерегез. Файдаланылган җөмләләрнең номерларын языгыз яки тексттан цитата китерегез.

## БЕЛЕМ ҺӘМ КҮНЕКМӘЛӘРНЕ БӘЯЛӘҮ НОРМАЛАРЫ:

*Уку күнекмәләре түбәндәгечә бәяләнә:*

Билгеле булганча, *дөрес уку* — әдәби әйтелеш кагыйдәләрен саклап, текстны хатасыз итеп уку. Ул балаларның әйтелеш һәм текстны аңлы рәвештә кабул итә алу күнекмәләреннән чыгып бәяләнә. Укучы аваз, иҗек һәм сүзләрне кабатламыйча, аларны төшереп калдырмыйча, урыннарын алыштырмыйча, грамматик формаларын бозмыйча һәм дөрес әйтелешкә карата куела торган иң төп таләпләрә җавап бирерлек дәрәҗәдә укыганда гына дөрес укый дип әйтә алабыз.

*Йөгерек уку* — укыганның эчтәлеген аңлы рәвештә зиһенгә алуны тормышка ашырырга ярдәм итүче уку тизлеге. Гадәттә, кычкырып уку тизлегенең сөйләм тизлегенә туры килүе уртача уку тизлеге дип исәпләнә.

*Сәнгатьле уку* текстның эчтәлеген аңлап, автор әйтергә теләгән фикер, хисләрне тавыш, басым һәм башка барлык просодик чараларны дөрес кулланып укый алуны белдерә.

*Аңлап уку,* ягъни текстның төп эчтәлеген аңлау һәм аңа карата үз карашыңны яки мөнәсәбәтеңне белдерә алу сәнгатьле укуга ирешүнең төп шарты булып тора.

Рус мәктәпләрендә укучы татар балаларының 1 минутта кычкырып уку тизлеге түбәндәгечә бәяләнә:

8-9 нчы сыйныфларда иҗекләр саны 160 -120 сүз, сүзләр саны 90-110 сүз.

1.Укучы билгеләнгән күләмдә сүзләрне дөрес һәм җөмләләрне сәнгатьле итеп, тулысынча аңлап укыса, «5» ле куела.

2. Уку тизлеге гомуми таләпләргә туры килсә һәм текст эчтәлеге буенча укытучы сорауларына җавап бирә алып, уку барышында 1-2 әйтелеш хатасы һәм сөйләмнең структур бүленешендә берничә төгәлсезлек җибәрелсә, «4» ле куела.

3. Уку тизлеге программада каралган таләпларгә туры килмәсә, текст эчтәлеге буенча укытучы сорауларына җавап биргәндә, төгәлсезлекләр җибәрелсә, дөрес әйтелешкә бәйле һәм сөйләмнең төп структур берәмлекләренә бүлгәндә 3-5 төгәлсезлек күзәтелсә, «3» ле куела.

4. Уку күнекмәләре тиешле тизлектән шактый түбән булып, текст эчтәлеген өлешчә аңлап, 5-6 дан артык әйтелеш хатасы җибәрелсә, «2» ле куела.

## СОЧИНЕНИЕНЕҢ КҮЛӘМЕ ҺӘМ АНЫ БӘЯЛӘҮ:

Әдәби (хикәяләү, очерк, истәлек, хат, рецензия һ. б.), әдәби-иҗади, өйрәтү характерындагы, ирекле, рәсемнәр нигезендә үткәрелә торган һәм контроль сочинениеләр була.

Сочинение план нигезендә языла. Ике сәгать дәвамында сыйныфта язылган *сочинениенең күләме* түбәндәгечә булырга тиеш: 5 нче сыйныфта 0,5—1 бит, 6—7 нче сыйныфларда 1—2 бит, 8 нче сыйныфта 2—2,5 бит, 9 нчы сыйныфта 2,5— 3,5 бит, 10—11 нче сыйныфларда 3,5—6 бит.

1. Язманың эчтәлеге темага тулысынча туры килсә, фактик ялгышлары булмаса, бай телдә, образлы итеп язылса, стиль бердәмлеге сакланса, «5» ле куела. (Бер орфографик яисә ике пунктуацион (грамматик) хата булырга мөмкин.)
2. Язманың эчтәлеге нигездә темага туры килсә, хикәяләүдә зур булмаган ялгышлыклар күзәтелсә, бер-ике фактик хата җибәрелсә, теле бай, стиль ягы камил булып, ике орфографик, өч пунктуацион (грамматик) яисә бер-ике сөйләм ялгышы булса, «4» ле куела.

3. Эчтәлекне бирүдә җитди ялгышлар, аерым фактик төгәлсезлекләр булса, хикәяләүдә эзлеклелек югалса, сүзлек байлыгы ярлы булса, стиль бердәмлеге дөрес сакланмаган җөмләләр очраса, өч орфографик, дүрт пунктуацион (грамматик) яисә өч-дүрт сөйләм хатасы булса, «3» ле куела.
4. Язма темага туры килмичә, фактик төгәлсезлекләр күп булып, план нигезендә язылмаса, сүзлек байлыгы бик ярлы булса, текст кыска һәм бер типтагы җөмләләрдән торып, сүзләр дөрес кулланылмаса, стиль бердәмлеге сакланмаса, биш орфографик, сигез пунктуацион (грамматик) яисә дүрт-алты сөйләм хатасы булса, «2» ле куела.

Татар урта мәктәпләре өчен татар теле программаларында диктант, изложение һәм сочинение яздыруга куелган таләпләр, нигездә, рус мәктәбендә укучы татар балаларына да туры килә.